Sabira Stahlberg

# Filip häm toman



aybagar

**Sabira Stahlberg**

# Filip häm toman

**Fazile Nasretdin tärcemäse**
**Maria Viitasalo räsemnäre**

Helsinki 2022

*Tampere tatar cämiyätenä (Tampereen tataariseurakunta, per. 1943), Finlandiya İslam Cemaatinä (Suomen Islam-seurakunta, per. 1925) häm Oskar Öflund vakıfına matdi yärdämnäre öçen samimi rahmätlärebez.*

OSKAR ÖFLUNDS STIFTELSE

**Ciñel tel däräcäläre**
Däräcä 1: İñ ciñel
**Däräcä 2: Ciñelräk**
Däräcä 3: Ciñel

Tatar, 2. basma / edition
Şved telendä/Original: *Filip och dimman*
Tärcemä: Fazile Nasretdin
Eş törkeme: Albina Samarhan,
Kamer Yafay Nogmanov, Derya Samaletdin,
Adile Samaletdin, Liliä Däülät

© Sabira Stahlberg 2022
© Fazile Nasretdin, tärcemä / translation 2022
© Maria Viitasalo, räsemnär / illustrations 2022

Bokpil ▸ bokpil.eu
Aybagar ▸ aybagar.eu
Helsinki 2022

ISBN 978-952-7334-46-1 (Kägaz kitap)
ISBN 978-952-7334-47-8 (E-kitap, PDF)

# Bülem 1

Bügen Filipneñ tugan köne.
Ul anı öydä ailäse häm
tugannarı belän bäyräm itä.
Barça tugan-kardäşläre
diyärlek kunakka kilä.

Filip tort peşergän.
Tortnı änise peşerergä telägän dä,
Filip yärdäm kiräkmi dip belgertkän.
Tort üzençälekle.
Filip anı üze uylap çıgargan.
Ul üzeneñ tortı belän gorurlana.

Tort Cir şarına ohşatıp yasalgan.
Tösläre zäñgär häm yäşel.
Bizäü öçen Filip kara ciläk şirbäte
häm bötnek yafrakları kullangan.
Küpertelgän kaymaktan
taularga ak tübälär yasagan.
Kotıplardagı boz da ak.
Tortnıñ çülläre sarı.
Alar öçen Filip ber banan izgän.

Filip Cir şarı turında kaygırtuın
kunaklarına kürsätergä teli.

Ul klimat üzgäreşläre turında
gel uylanıp yöri.
Tönyak häm Könyak kotıblarında
boznıñ erep baruı anı iñ küp borçıy.

Filip hayvannarnıñ küp törläre
yugala dip tä kaygıra.
Ul hazerge vakıtta Cir turında küp ukıy.
Nigä klimat üzgärä häm
üze ni eşli alır ide dip tä beläse kilä.

Üzgäreşlärne tuktatır öçen
keşelär ni bulsa eşli alalarmı?
Älegä Filip belmi.
Törle çaralar turında uylana.

Sofia kuzinı häm Bibinur apa
kilep citkännär inde.
Alar başka şähärdä yäşilär.

Sofia belän tagın oçraşkanga Filip şat.
Anıñ belän söyläşü küñelle.
Ul da tabiät belän kızıksına.
Küreşkändä Filip belän
Sofia hayvannar,
diñgez häm küp başka
küñelle närsälär turında
sägatlärçä söyläşälär.

Başkalar tıñlap torırga tuyalar da,
kaçıp kitälär.

Bibinur apa harvakıttagıça
Filipneñ açuın kiterä.
Pudelen da kitergän häm
şul näni Bikbayı öçen
böten vakıt tınıçsızlanıp tora.
Et närsädän genä hastalana ala dip
Bibinur apa şiklänep tora.
Ayıruça Filipneñ tortı
Bikbaynıñ aşkazanın
bozarga mömkin dip äytä.

Ayaz abıy tagın da soñga kalgan.
Filip abıyın yarata.
Ul apadan bötenläy ayırılıp tora.
Ayaz tınıç häm akıllı.
Anıñ Filip belän söyläşergä
haman vakıtı bar.

Ayaz küp säyähat itä häm
kürgän-kiçergännären söyli.
Alar ikäü möhim eşlär
turında söyläşälär,
mäsälän, kit niçek tiz yözä ala.
Filipneñ närsälär yaratkanın
Ayaz bik yahşı belä.

Hazer inde kardäşlär östäl artında
utıralar da kahvä häm çäy eçälär.

Äbä äni belän apa arasında utıra.
Ul apa belän söyläşä.
Filip äbägä karıy da,
beraz küñele töşä.
Babaynıñ ülgänenä tizdän ber yıl bula.
Filip babaynı sagına.

Äbä yalgız kaldı.
Ul ise kitmägängä salışsa da,
üzen yalgız his itä.
Anı barısı da belä.
Kayvakıt äbä köngä
berniçä tapkır şaltırata
häm şul uk süzen kabat-kabat söyli.
Ul söyläşergä genä teli dip äni äytä.

Äbä iltifatsız bula başlagan.
Äüväl bik yämle kiyenä ide.
Matur altın-kömeş bizänü äyberläre bar ide.
Barısı da anıñ zävegına soklanalar ide.
Soñgı aylarda altın-kömeşlären dä takmıy.
Äbäneñ külmäge yış böreşkän
häm anda-monda taplar bar.

Bügen tagın äbä kiyemen ütüklärgä onıtkan.

Ul turıda berkem dä bernärsä äytmi.
Äytergä kileşmi dip uylıylar kardäşlär.

Äbä üze beraz kartaydım
gına dip uylıy.
‒ Filip, añlıysıñ bit,
anıñ şundıy äytä torgan adäte bar.
‒ Keşegä kartaygaç onıtırga yarıy.
Kayçan bulsa äyberlär dä yugala.
Başım ber dä eşlämi.

Filip alay uylamıy.
Äbäy äbä kebek uk kart,
läkin äbäy ütken.
Berkayçan da bernärsäne dä onıtmıy,
äyberlärne dä yugaltmıy.

Äbäy härvakıttagıça citez.
İşek kıñgıravı çıñlıy.
Filip işekne barıp aça.
Ayaz kiñ itep yılmayıp
boldırda basıp tora.
‒ Tugan köneñ kotlı bulsın, Filip!
dip kıçkırıp cibärä.
Filipne kısıp koçaklıy.

‒ Menä sin telägän kitap,
Ayaz äytä.

– Bu kitap keşeneñ häm
hayvannarnıñ psihologiyäse turında.

Filip alarnıñ üz-üzlären totışları
turında ukırga yarata.
Nigä keşelär häm hayvannar
üzlären törleçä totalar,
anı Filip belergä teli.

Filip abıysına rahmät ukıy da,
kitapnı karıy başlıy.

– Bügen kiçen ukırsıñ, abıy äytä.
– Ä häzer tugan-tumaçalarnıñ
hallären beleşäbez.

Alar başkalar yanına baralar.
Ayaz abıy äbä yanında tuktıy da:
– Änkäy, bluzaññı
ütüklärgä onıtkansıñ!
dip äytä.

# Bülem 2

Kiläse atnaraskönne äni
Filipkä äbägä barmassıñmı dip äytä.
Adättä äni üze bara,
läkin kiç belän alarga kunaklar kilä.
Änigä kiçke aşnı äzerlärgä kiräk.

‒ Yaña gına ikmäk saldım,
ästerhan çiklävege belän, äni äytä.
‒ Äbäneñ iñ yaratkan ikmäge bu.
Alıp barırsıñ bit?

Äbä Filiplärgä yakın yäşi.
Cäyäü barırga un minut ütä.
Äbä küptän tügel yaña fatirga küçte.
Elek yıraktarak tora ide,
ämma hazer änigä
yakınrak yäşärgä teli.

Bibinur apa başka şähärdä yäşi häm
Ayaz abıy yış çit illärdä yöri.
Filipneñ änise gel öydä
häm ul äbägä bulışa ala.

Filip cılı ikmäkne alıp
äbä yanına kitä.

– Hey Filip, äbä äytä.
– Yahşı itteñ, kildeñ.
Yaratkan ikmägemne dä
alıp kilgänseñ!
Utır, päynirle ipilär aşıyk.
Çäy kuyam.
Bälki şirbät teliseñder?

– Rahmät, çäy, Filp äytä.
– Bötnek häm bal belän.
– Hazer bula, äbä cavap birä.
– Mäktäptä eşlär niçek bara?
Dustıññıñ hale niçek?
İseme niçek ide? Kamil? Şamil?

– Halil, Filip cavap birä.
– Ul haman oçkıçlar yasap toramı?
äbä sorıy.
– İnjener bulırga teli ahrısı?
– Yuk, Halil himiyänı yarata, Filip äytä.
– Ul oçkıçlarnı yaratmıy.
Himik bulırga uylıy.
– Oy, alaysa yalgışam, äbä äytä dä,
aptırap kalganga ohşıy.

– Minem sıynıfımdagı Mimi
oçuçı bulırga teli, Filip äytä.
– Ul oçkıçlar belän kızıksına.

Läkin ul üze alarnı tözemi.
Oçarga gına teli.
‒ Säyer, dip äbä mıgırdıy.
‒ Härkemneñ üz şögıle bulırga tiyeş,
şulay bit?
Äbä aşhanägä kerep yugala.
‒ Nigä kemder közgeneñ urının alıştırgan,
söylängän tavışı işetelä.
‒ Haman, şunda bäreläm.
Miç tä urınında tügel.
Tönen bädräfne tapmıym.

‒ Äbä, sin bit küçteñ, Filip äytä.
‒ Künärgä vakıt kiräk.
‒ Filip, mine kart äbäñne
kerep bakkan öçen min bik şat.
Äle añlatçı, sin nilär eşläp yöriseñ?
äbä sorıy.

Filip añlata başlıy.
Ul äbä belän söyläşergä yarata.
Äbä härnärsä belän kızıksına.
Bik äybät tıñlıy da,
berkayçan ahmak soraular birmi.

Läkin äle ul çınnan da tıñlamıy dip Filip sizä.
Eşlärne dä butaştıra.
Äbäneñ kulında täpse.

Täpsedä çogırlar,
tabaklar häm bal kaşıkları.
‒ Bal!
Sin bal telägän ideñ bit.
Anı onıttım, äbä äytä.

Kinät äbä abınıp kitä.
Filip tiz-tiz tora da, täpsene
çak kına totıp alırga ölgerä.
‒ Kan basımı, äbä äytä.
‒ Tabib birgän daru yahşı tügel.
Miña daruhanädän
yaña daru barıp alırga kiräk.
Läkin minem eşem bik küp,
anda barırga vakıtım yuk.

Filip täpsene östälgä kuya da:
‒ Äbä, çäynek kayda?
Ä kaydan yangan is kilä?
dip sorıy.
Aşhanägä kerä.
Äbä miçneñ döres küzen
kabızmagan ikänen kürä.
Ul su kaynatır öçen ber
yumagan kazannı kaynarga kuygan.

‒ Kazannıñ töbe yangan,
äbäse Filipneñ arkası artında äytä.

Anı taşlarga kiräk, diyä.

Annarı beraz äkren tora da:
– Filip akıllım, äniyeñä berni dä
äytmässeñ bit?
Ul härnärsä öçen
minem belän talaşa.
Kazan möhim tügel.
Vakıtıñ bulganda
miña şundıy uk kazan
satıp alırsıñmı?
Menä siña akça.

– Älbättä, Filip äytä.
– Bu bezneñ ser bulsın,
äbä äytä dä küz kısa.

# Bülem 3

Berniçä könnän soñ Filip kazan satıp ala.
Anı äbägä iltä.
Äbä şatlana da,
Filipne kısıp koçaklıy.
– Rahmät, akıllım!
Niçek miña kazan
kiterergä uyıña kilde? sorıy.
– Sin monı minnän soragan ideñ bit,
Filip ise kitep äytä.

Ni bulgannı Filip açık itep añlamıy.
Äbä iske kazan
töben yandırganın haterlämime?
Filip äbäne küzätä.
Äbägä nider bulgan.
Ul üzgärgän.
Ös-başın bakmagan.
Çäçe küptän yuılmagan.
Öyendä sası is.

Äbä öyen cıyıştırmıy ahrısı.
Aşhanäneñ astı öskä kilgän.
Savıt-saba yu´u urınında häm östäldä
tälinkälär, çäneçkelär, pıçaklar
öyem-öyem tora.

– Äbä, siña bulışsam,
yararmı? Filip sorıy.
– Min çüplärne çıgarıp taşlıym?
Savıt-sabalarnı da yualam.
– Kiräk tügel, äbä äytä.
– Kiçä çüplärne taşlagan idem.

Filip aña karap ala.
Äbä yalgışa.
Ul çüplärne ber atna buyı taşlamagan.
– Min çüplärne alıp çıgam,
Filip nık kına äytä.
– Sau bul, küreşerbez.
Yahşı tor.

Filipneñ küñele töşä.
Sası isle kapçıknı ırgıta da,
avır adımnar belän öygä taba kitä.
Äbä ni öçen şundıy säyer ikän?
Nigä öyen cıyıştırmıy?

Babay äle isän vakıtta
öyläre haman ap-aru
häm tärtiple ide.
Babay hasta bulganda
äbä barısın da kaygırta ide.
Kiçke aştan soñ çüplärne
härvakıt taşlıy ide.

Äni belän söyläşergä kiräk,
Filip uylıy.
Ul, älbättä, ni bulgannı beläder.

Läkin öygä kaytkaç, äni belän
söyläşergä hiç tä mömkinlek tapmıy.

Ayaz abıy divanda utıra.
Telefonı östäldä.
Anı küzätep tora.
Ayaz kırıs kürenä.
Änineñ küzläre kızıl.

– Filip! Anda ikänseñ, äni äytä.
– Sineñ turıda söyläşäbez.
Niçek sin şundıy ädäpsez bula alasıñ?
Äbäneñ pensiyäse bik az,
sin anı belmiseñme?

– Filip akçalarnı urlagan dip hiç tä
uylamıym, Ayaz äytä.
– Närsä turında söyläşäsez? Filip sorıy.
– Äbä Bibinur apaga şaltıratkan.
Äbäneñ öyennän akça yugalgan.
Akçalarnı sin urlagansıñ dip
apa uylıy, äni äytä.

– Bibinur apa baya gına şaltırattı.

Äbä akçalarnı döres sanamagandır
dip uylım, Ayaz östi.
– Äbä härzaman tugrılıklı, äni äytä.
– Min belgän keşelärdän iñ tugrılıklısı.
Ul säbäpsez berkayçan
da berkemne dä ayeplämäs.
– Äbä ayeplämi bit,
apa Filipne ayepli,
Ayaz iskä töşerä.

– Min äle añlıy almıym, Filip äytä.
– Äbä sin kitkäç, yänçegendä
akçalar yuk dip sizgän, Ayaz äytä.
– Atna ahırında sin genä
anda kerep çıktıñ, äni äytä.
– Ämma....Filip başlıy,
läkin änise anıñ süzen bülä:

– Filip, akçalarnı şunda
uk kire kaytar!
Niçek alay eşli aldıñ?
Äbäññän niçek urlıy aldıñ?
Siña kesä akçası biräbez bit.
Citmime?

– Min Filipkä ışanam, Ayaz äytä.
Älbättä, bu eşkä başka cavap bardır.
Şulay bit, Filip? Ayaz östi.

Filip tirän sulap ala.
Äni niçek apanıñ süzenä ışana ala?
Nigä ul min äbädän
urladım dip uylıy?
Bu berkayçan uyıma da kilmäs ide.
Nigä Bibinur apa mine ayepli?

Apa haman şundıy inde.
Ul Filipne yaratmıy häm
haman yalgış näticälär yasıy.

– Äbä miña akça birde,
Filip äytä başlıy.
– Döres tügel,
äni Filipneñ süzen bülä.
– Äbä siña akça birmägän dip äytä.
Äbä berkayçan da yalgan söylämi.
– Filipne tıñla, Ayaz äytä.

Filip beraz vakıt uylap tora.
Serne söylärgä mikän?

Ul bit äbägä berni dä
söylämäskä süz birde.
Serne biräse kilmi.
Filip üzen hıyanätçe dip toya.
Alay bulsa da eş niçek
ikänen äytergä yahşıraktır.

‒ Äbä kazan töben yandırdı.
Yaña kazan alır öçen
miña akça birde.
Kazannı ozak ta tügel
äbägä ilttem.
Läkin ul anı soraganın haterlämäde,
Filip añlata.

‒ Filip, sin yalgan söyläsäñ,
betteñ, äni kurkıta.
‒ Äle kuyırtasıñ, Ayaz abıy äytä.
‒ Kayvakıt Filip nider başınnan uylap
çıgarırga mömkin dä,
akça yäki başka citdi eş
turında yalgan söylämäs ul.

Ayaz divannan tora da, äytä:
‒ Äbägä barabız da,
barısı da anda yahşımı
dip tikşeräbez.
Min çınnan da äbä turında
borçıla başladım.

Äni, Filip häm Ayaz äbä yanına kilälär.
Äni işek kıñgıravına basa.
Berkem dä kilep açmıy.
Açkıçın çıgarıp, äni
işekne açıp cibärä.

Äbä öydä tügel.
Filip tup-turı aşhanägä barıp kerä.
– Tegendä min satıp
algan kazan häm
menä hisabı, kürsätä.
– Menä kalgan akçalar.

Kazan äle dä algan köyendä,
törelgän kileş.

– Beldem bit, Ayaz abıy äytä.
– Filip ayepsez.
Ämma kayan mondıy sası is kilä?

– Äbä öyen cıyıştırmıy
inde, Filip äytä.



# Bülem 4

Ayaz abıy äbäneñ öyen äylänep çıga.
– İske aş kaldıkları, dip mıgırdana.
– Östäl östendä ipi valçıkları häm taplar.
Yuınu bülmäse pıçrak.
Äbä härhaldä ike atna buyı
tuzannarnı suırtmagan.
Kerlär yuılmagan.
Acäp, äbä öyen niçek karıy?
TV kabıngan, dimäk, ul yırakka kitä almagan.

Äni urındıkka utıra.
– Min ışanalmıym, dip äytä.
– Afu it, Filip, sinnän şikländem.
Apañ sin dip mine inandırdı.
Bibinurga tügel, min üzemä
ışanırga tiyeş idem.
Äbä hateren yugaltkan ikän.

– Şulay äkren-äkren bula, Ayaz äytä.
– Äbä hateren äz-äzläp yugaltkan.
Andıy hal, omumän,
ni bulsa bulgaç kına sizelä.
Filip, sin kibetkä yögerep barıp,
sorap karıysıñmı?
Äbäne kürgännärme?

Ul arada bez monda öyne cıyıştırabız.
Filip çıgarga tora.
Äninseneñ küzläre
yäş belän tulgannı kürep ala.

Ayaz abıy änine yuatırga tırışa:
– Kartlıktan, Ayaz äytä.
– Küp keşe mondıy
avırlıklarga duçar bula.
Bez moña ni dä eşli almıybız.
– Nigä bezneñ äniyebez? äni üksi.
– Nigä ul äüvälge kebek köçle
häm şat tora almıy?

Filip işekne yabıp çıga.
Anıñ kulları kaltırıy.
Änise dä äbäse öçen borçıla.
Äbä kayda bula ala?
Tışka çıkkanda nigä TV ne
kabızıp kaldırgan?

Soñgı vakıtlarda ul bik säyer.
İske zaman turında gına söyli.
Filipneñ gel tıñlıysı da kilmi.
Şul uk hikayäne ul
äzdän unbiş kat işetkän.

Bälki dä äbäneñ tormışı kızık tügelder?

Anı bernärsä dä artık kızıksındırmıy inde.
Dusları da küp kalmadı,
berkem kerep tä bakmıy.
Äbä gäzitä ukıy, TV karıy,
läkin tirä-yagında nilär bulganga
ise dä kitmi.

Aña kiräge yuk.
Äbä ütkännärdä yäşi häm
iske eşlär turında uylana.
Kayvakıt babay äle
isän kebek söyläşä.
Filip başın çaykıy.

Min äbäneñ säyer buluı turında
uylarga tiyeş tügel.
Äbäne niçek tabarga,
miña şul turıda uylarga kiräk.
Filip kibetkä kerä.
Kibet äbä yäşägän yort yanında uk.

Filip kiştälär arasında yörenä,
läkin anda äbä kürenmi.
Kassaga bara da, kassaçı apadan
äbäne kürgänme dip sorıy.
Apa äbäne dä, Filipne dä belä.

– Äye, kassaçı äytä.

– Ul biredä ide.
Çigeldäk satıp aldı.
Yegerme minut äüväl monnan çıktı.

– Kaysı yakka kitkänen kürdeñme?
Filip sorıy.
– Uylıym, şähärgä taba kitte,
kassaçı äytä.
– Minemçä beraz säyer.
Ul berkayçan da şähärgä
cäyäü kitmi ide.

– Ul adättä autobus belän
bara, Filip äytä.
– Yırakka yörergä ayakları çıdamıy.

Filip aşıgıp-aşıgıp
äbäneñ öyenä kayta.
Abıy belän äni iske gäzitälär häm
şeşälär cıyıp toralar.
– Äbä şähärgä taba cäyäü kitkän,
yögerüdän tını kısılgan, Filip äytä.
Änineñ yöze agara.
– Tiz-tiz.
Bezgä äbäne karañgı töşkänçägä kadär
tabarga kiräk, äni äytä.

# Bülem 5

Ayaz abıy poliska şaltırata.
– Hatere haman eşlämi,
telefon aşa äytä.
– Tışkı kıyafäte? polis soraşa.
– Pältäse yäşel häm
itekläre kara, Ayaz añlata.
– Haterläü avırıuı bulgan keşe
turında süz bara? polis sorıy.
– Äye, hatere yagınnan avırıy torgan
keşe dip äytep bula.
Beläm, sezgä alarnı yış kına
ezlärgä turı kilä.
Läkin bu minem äniyem,
häm dä bu mäsälä minem öçen berençe.

Filipneñ eçenä güyä salkın
boz kisäge kerep utıra.
Äbä avırıy.
Şuña kürä ul bik säyer.
Hateren yugaltu gına tügel,
bu hastalık.

Filip kaltırana.
Üzen bik naçar his itä.
Keşe niçek kinät eştän çıga ala?

Närsä anı üzgärtä?
Nigä?
Häm dä min ni eşli alam?
Äni ätigä şaltırata,
ämma ul cıyılışta, cavap birmi.
‒ Monı bezgä üzebezgä hal itärgä kiräk,
dip äni körsenep kuya.

‒ Zur uram buylap üzäkkä taba barabız.
Äbä şul yul belän baradır.
Min uramnıñ uñ yagınnan baram,
sin sul yagınnan, änigä Ayaz äytä.
‒ Filip, sin kem belän barasıñ, sayla.
‒ Min yalgız baram, Filip äytä.
Aña uylarga kiräk.
Anı Ayazga äytergä telämi.

Uramga çıgalar da,
Filip tup-turı alga kitä.
Anıñ başında törle uylar äylänep yöri.
Açık uylarga tırışa.
Äbägä ni bulsa bulganmı ikän?
Anı niçek tabarga?
Äbäneñ uylau ısulın küz aldına kiterä.
Äbä kaya barır ide ikän?
Tukta, autobus belän kitkän bulsa?

Autobus.

Älbättä!

Filip tirä-yagına karıy.
Abıy belän äni, ikese dä,
tuktagannar da, äbä turında soraşalar.

Uramda tanışları belän fikerläşälär.
Karañgı töşä dä, fänärlär kabına.
Uram östenä toman töşä.
Toman kuyıra bara.

Filip köçkä yöz meter alga kürä.
Äle äbäne tabarga aşıgıç.
Toman eçendä yuldan
adaşırga mömkin.
Filip autobus kilgänne kürä.
Tiz bulırga kiräk.
Änigä häm Ayazga
berni äytergä ölgermi.

Autobuska kerä dä,
öç tuktalıştan soñ töşä.

Autobustan töşkäç
ber yortka barıp kerä.



# Bülem 6

Elektän äbä bu yortta yäşi ide.
Filip öçençe katka yögerep menä.
Döres uylagan.
Ber işekneñ aldında äbä basıp tora.
Aptıraganga ohşıy.
Çäçe törle yakka taralgan.
Pältäse ber cilkäsendä sälenep tora.
Ul anı salırga tırışkan, küräseñ.

Äbä iske öyenä kaytkan.
Filipne kürgäç, yöze yaktırıp kitte.
– Sälam, äbä şatlanıp äytä.
– İnde yahşı, kildeñ.
Açkıç belän problem bar.
Ul bikkä kermi.
Sin açalsañ,
çäy häm çigeldäk biräm.
Kibetkä kergän idem.

Filip kölä.
Rähatlänep kitä.
Läkin ber ük vakıtta yörägen
salkın kul yomarlaganday toya.
– Äbä, sin monda tormıysıñ inde,
Filip äytä.

– Bu sineñ iske öyeñ.
Äle kaya torganıñnı min hazer kürsätäm.

– Yuk-barnı söyliseñ, äbä mıgırdıy.
– Min monda toram.
Nik min başka cirdä toram di?
– Sin bit küçteñ, haterliseñme?
Sin äle bezgä yakın torasıñ.
Filip äbägä borçılıp karıy.
Küçengänen haterli mikän
yäki onıtkan mikän?

Äbä mañgayın tota.
– Äye şul, bik döres äytäseñ,
kıçkırıp cibärä.
– Äle haterlim.
Ämma nik min monda?
Niçek şundıy ahmak bulırga inde?
Min dönyanıñ iñ ahmak däü äniseder.
Niçek mondıy tile bulırga?
Äniyeñä bernärsä dä
äytmässeñ bit, Filip?

Äni belän abıy anı ezlilär bit.
Anı äbäsenä añlata.
– Alaysa berni dä eşläp bulmıy, äbä äytä.
– Haterem elekkege kebek eşlämi.
Bezgä monı belep yäşärgä kiräk.

Filip änisenä şaltırata,
läkin anıñ telefonı mäşgul.
Ul äti belän söyläşäder.

Filip Ayaz abıyga şaltırata.
Abıy şunda uk Filipkä yärdäm
kiräkme, dip sorıy.

‒ Yahşı, Filip äytä.
‒ Äbä yöri ala bit.
Autobus belän kaytabız.
Filip äbä belän tuktalışka taba bara.
Äbä berni dä äytmi.
Autobusta da äkren genä utıra.
‒ Äbä, haterlämiseñ dip kaygırma, Filip äytä.
‒ Eşlärne onıtu normal.
Üzeñ dä kartaydım dip äytäseñ bit.

‒ Ämma bu hiç tä döres tügel, äbä äytä.
‒ Kayda torganımnı beläm bit.
Bu kadär oyatka berkayçan da
kalganım yuk ide.
Siña, äniyeñä, ätiyeñä
häm Ayaz abıyıña minnän mäşäkat kenä.

Äbä beraz uylap tora da:
‒ Haterem artık eşkä yaramıy.
Anı caylarga kiräk yäisä yañasın alırga.

Sin beläseñme,
kayda yaña haterlär satalar?

Filip kölä.
Äbäneñ humorında bernindi zıyan yuk.
– Bu bez çıga torgan
urın tügelme, äbä sorıy.
– Yuk, Filip äytä.
– Kiläse tuktalış.

– Yahşı kürmim dä inde, äbä dävam itä.
– Tizdän kürüemne häm işetüemne
dä yugaltırmın inde.
Uylap karaçı,
kartalar yortına eläksäm?
Min anı bötenläy telämim.
Miña kalsa, kartlar yortı iñ naçar urın.
Ä kuzgala da almasam, ni bulır?
äbä töyelep äytä.

Filip äbäne yuatırga tırışa,
läkin ul tıñlamıy kebek.
Autobustan töşkändä äni belän
Ayaz abıy alarnı kötep toralar.
– Sez kayda idegez,
äni borçılıp kıçkırıp cibärä.
– Elekke fatiriña barırga inde.
Andıy ahmak fiker uyıña niçek kilde?

– Autobus belän bardım, äbä añlata.
– Äbägä kanıkma, Ayaz äytä.
– Äle öygä kaytabız.

Filip äbäse belän tın gına bara.
Änise bertuktamıy söyli.
Anıñ aptırap kalganın Filip kürä.
Äniseneñ borçılganın añlıy da,
äbä öçen anıñ faydası yuk.

Filip änisenä bik nık açulana.
Şul uk vakıtta änise öçen borçıla da,
Filip änisen berkayçan da mondıy
yarsulı kürgäne yuk.

Äbä üz-üzenä yılmaya.
Nindider cır köyläp bara.
Änineñ äytkännärenä ise dä kitmi.
Söyläven işetmi dä kebek.

# Bülem 7

İkençe könne Bibinur apa şaltırata.
– Sez äbäne tabibka alıp
barırga tiyeş, dip telefonnan kıçkıra.
– Uylap karagızçı,
aña närsäder bula kürsä?
Niçek sez mondıy iltifatsız bula alasız?
– Tınıçlan, äti äytä.
– Bez kiläse atnada
barırga vakıt aldık inde.

Äni Bibinur apa belän söyläşergä telämi,
annan borçıla gına.
Bibinur apa bik küp kiñäşlär birep tora,
ä üze äbä belän oçraşırga da telämi.

– Eşem bik küp.
Vakıtım yuk.
Yärdäm itär öçen berni dä eşlämi.
Äbäne Filipneñ änise genä bagarga tiyeş.

Äle äni kön sayın äbä yanına bara.
Öy cıyıştırılgan.
Sası is tä kilmi inde.
Äbä äle dä tabibka barırga telämi.
– Nigä min tabibka barırga tiyeş,

dip sorıy ul.
Min bit sau-sälamät.
Haterem genä beraz iske.

‒ Üzeñne tikşertsäñ, yahşırak bit,
Ayaz abıy äytä.
‒ Annarı nindi darular kiräk, belerbez.
‒ Miña bernindi dä
darular kiräkmi, äbä äytä.
Minem halem bik yahşı.
Omerem buyı üzemne
üzem karadaım,
nigä äle karıy almas idem?
Miña niçek yäşärgä kiräk,
anı min üzem iñ yahşı beläm.

Äbäneñ borçılganın Filip sizä.
Tagın eçendä boz kisäge oyışkannı toya.
Äüväl äbä tınıçsız tügel ide.
Şat häm tıynak ide,
tabibka da teläp bara ide.
‒ Barısı da yahşı bulsın ide,
tikşertergä kiräk, dip äytä ide.

Tabibka barırga ber sägat kalgaç, öçäü ‒
Filip, äni häm äti äbägä baralar.
Äbä hazer gına torgan.
Yuınmagan, kiyenmägän dä.

Alarnıñ kilüennän tınıçsızlana.

Öydä arı-bire äyberlären
ezlänep yörenä.
Yänçege yugalgan,
kulyaulıkların da tapmıy.

‒ Tabib? Bügen?
dip kıçkırıp cibärä.
‒ Koçatnakönne tügelme ide?
Nik kiçä berni dä äytmädegez?
Nik kiler aldınnan şaltıratmadıgız?
Başımnı haman butaştırasız.



# Bülem 8

Tabib äbägä yaña darular kiräk dip äytä.
Äni darularnı satıp ala häm
äbä alarnı kabamı dip küzätergä tırışa.
Ämma äni yış öydä yuk,
kurslarda häm seminarlarda bula.
Ul çaklarda äti, abıy häm Filip
äbägä baralar.

Bibinur apa härkön şaltırata da,
üget-näsıyhat birä.
Läkin üze kürenmi dä,
Sofiaga da äbä yanına yalgız
kilergä rohsät birmi.

Berniçä aydan soñ Ayaz abıy
Filiplärneñ işek kıñgıravın şaltırata.
Üze bik citdi kürenä.
Ul äbäneñ halen tikşerter
öçen anı tabibka alıp bargan.

– Äbäne kartlar yortına
urnaştırırga kiräk,
Ayaz abıy äytä.
– Ozaklamıy äbä öyendä yalgız tora
almas inde dip tabib miña añlattı.

– Yuk, di äni.
Yuk, berniçek tä mömkin tügel.
Äbäneñ üzeneñ fikere buyınça,
barısı da yahşı.
Öydä torsa, anı yahşı
kararga gına kiräk.
Ul eşne bez kaygırtırga tiyeşbez.

– Äbä kartlar yortına barırga telämi,
Filip östi.
– Anda ozın koridorlar häm
yalgız keşelär genä bar dip äytä.
– Sez anı üz öyegezdä
kararga telisezme? Ayaz sorıy.

– Andıy mömkinlegebez yuk,
di äti.
– Min äbäne karıy alam,
Filip süzne bülä.
– Mäktäptän soñ aş peşerä alam
häm öyne cıyıştıra alam.

– Yuk, alay bulmıy,
Ayaz cavap birä.
– Olı keşe öçen dä
bu bik avır eş.
Sinnän belemleräk
häm köçleräk keşe kiräk.

Ägär äbä yıgılsa,
ayagın sındırsa, nişlärseñ?
Yäki kinät açulansa da, siña suksa?

– Äbä miña berkayçan
da sukmıy, Filip katı äytä.
– Suga ala, telämäsä dä,
Ayaz äytä.
– Äbäneñ baş miye elekkeçä eşlämi.
Ul iskärmästän açulana häm
närsä dä bulsa eşli ala.

– Hosusi kartlar yortı yahşırak,
di äti.
– Anda anı äybät karıylar.
Anda törle şögıllär bar
häm rizık tämle.
– Monıñ öçen akçagız barmı?
dip Ayaz sorıy.
– Minem fatir öçen burıçım bar,
anı min tülärgä tiyeş.

– Nigä sosyal hezmäte yärdäm itmi,
äni mıgırdıy.
– Äbä öçen cämiyät närsä eşli?
Ul omere buyı eş eşlägän häm
yıllarça salım tülägän.
Ni öçen anı öyendä karap bulmıy?

‒ Karau öçen äbäneñ
akçası kullanıla,
Ayaz äytä.
‒ Amma ul kıymmätkä töşä.
Ozak yäşärme, berkem belmi.
İke yäki öç yıl, yäisä bälki dä un yıl?

‒ Sin äbä turında ul ülgän inde
kebek söyliseñ, äni äytä.
‒ Yuk, di Ayaz.
‒ Uyla beraz.
Äbägä yärdäm kiräk.
Uñaysız hal bulgannan äüväl
bu mäsäläne hal itärgä tiyeşbez.

‒ Bu döres tügel, di äni.
Äbä üzen karıy ala.
Aña tagın da küçärgä kiräk, dip
min äbägä äytä almam,
dip uylım?
Elek tä yaratmadı.
Äbä torgan cirendä kala.

Filip häm äti başların kagalar.
Alar äni kebek uylıylar.
Äbä üz öyendä yäşärgä tiyeş.
Berkemne belmägän,
yat cirdä tügel.

Bigräk tä anı berkem
tanımagan cirdä.
– Bez yakın torabız bit,
Filip äytä.

– Berni dä añlamıysız,
Ayaz açulanıp äytä.
– Bibinur apa sezgä karaganda
tagın da yamanrak.
Vakıtında yärdäm birmäsäk,
äbä öçen tagın da avırrak bula.
Yahşı karalmasa,
ul ülärgä mömkin.

Ayaz çıga häm
çıkkanda işekne bärep yaba.

# Bülem 9

Aylar ütä, Ayaz abıy
hiç şaltıratmıy.
Ul äbägä anda berkem
bulmaganda gına kilep kitä.

Äbä gel Ayaz turında söyläp tora.
Ayaz bik akıllı.
Ayaz bik yagımlı.
Ul barısınnan da zihenle
häm barısınnan da yahşı.
Äni belän Bibinur apa
Ayaz abıyga yakın da kilmilär.

– Bügen biyergä barasıñmı? äbä sorıy.
– Ni diseñ? äni äytä.
– Min yıllarça biyergä barganım yuk.
– Äye ämma..., äbä äytä.
– Alay bulsa, üzeñä ir niçek tabarsıñ?
– Min irdä inde,
balam da bar, äni äytä.
– Filip minem ulım, haterliseñme?
– Filip, ul kem? äbä sorıy.

Könnän-kön äbäneñ uyları
säyerräk bula bara.

Kayvakıt ul Filipneñ
kem ikänen haterli,
ämma yış ul kemneñ balası dip tä sorıy.

Äbä avırtularım bar dip tä zarlana.
Yoklıy almıym dip äytä, häm aştan da kala.
Aş peşerergä äbäneñ köçe citmi inde.
Ul kübesençä divanda yatıp TV karıy.

Filip närsäder soraganda äbä
yış cavap ta birmi.
Kuhnada kemder tavışlasa,
bik katı tınıçsızlana.
Kayvakıt Filipkä kıçkıra.
Ämma şunda uk
nigä açulanganın onıta.
Şunnan çigeldäk belän çäy kapçıkları
barıp kiterä dä, hava torışı turında añlata.

Äni bik arıgan, stress kiçerä.
Äti eştä yokıga kitä.

Berkönne äbä Filipkä
äni mine ütrergä tırışa dip añlata.

– Äniyeñ mine zähärlärgä teli, äytä.
– Ul peşergän rizıknı aşamıym inde.
Küse zähäre kuşkan.

Tämen sizäm.
– Ul sineñ daruıñ açı, Filip äytä.
– Yuk, ul zähär.
Daru tämen beläm,
üzsüzlänep cavap birä.
İkençe könne äbä aşamıy, baş tarta.
– Min Filip peşergänne genä aşıym, äytä.
– Filip miña aş peşersen.
Ul gına miña yahşı.
Başkaları hämmäse
ülgäç akçamnı gına telilär.

Äni bik açulana.
– Filipneñ eşe siña aş
peşerü tügel, äni äytä.
– Nik miña açulanasıñ?
Min siña närsä eşlädem?
äbä cavap birmi.
Täräzädän tışka karıy.

Şul uk könne kiçen äti citdi
räveştä äni belän Filipkä söyli:
– Siña yalga kitärgä kiräk,
änigä äytä.
– Bu bolay dävam itsä,
bez barıbız da hastalanabız.
Bez äle äbäne kartlar yortına
urnaştırırga tiyeş.

– Minem halemnän kilmi inde,
äni töyelep äytä.
– Köçem dä kalmadı.
Alay bulsa da anı kartlar yortına
urnaştırırga yaramıy.
Ul bit minem äniyem.
Ä min bulmaganda anı kem karar?

– Bez buldırabız,
şulay bit Filip? äti äytä.
– Kartlar yortı turında uyla.
Min üz fikeremne üzgärttem häm
äle min Ayaz belän ber fikerdä.

Filip başın iyä,
läkin bernärsä dä äytmi.
Eçendä zur salkın kisäk.



# Bülem 10

Äni yal itärgä kitä.
Änineñ sälamätlege
cimerelergä tora dip tabib äytä.
Här irtä häm här kiç Filip
ätise belän äbägä bara.
Aşnı äti peşerä dä,
Filip peşergän kebek kılanalar.
Şulay gına äbä aşıy.

İrtä belän Filip avır tora.
Ul uyatkıç sägatneñ
şaltıravın işetmägäç,
mäktäpkä barırga soñga kala.
Annarı Filip mäktäpkä
söyrälep barıp citä dä,
östäle artında yokıga kitä.

Halil anı adättä uyata.
Filipneñ däreslärne
utırıp tıñlarga köçe yuk.
Sabakların ukımıy.
Kulların yözenä kuyıp,
äbä turında uylap utıra.

Elek alar törle närsälär eşlilär ide.

Äbä Filipne muzeylarga
häm galereyalarga alıp bara ide.
Alar bergä räsemnär häm
häykällär karıylar ide.
Filipkä çigeldäk peşerergä öyrätkän ide.
Elek barısı da küñelle ide.

Älege zamanda äbäne uylau yöräkkä tiyä.
– Äüvälge äbäm kaya kitte?
Filip zarlana.
– Bu minem äbäm tügel.
Bu yat keşe.
Tışkı küreneşe dä üzgärä bara.
Täne kibä häm könnän-kön
keçeräyä bara kebek.

– Yahşı vakıtlarnı haterlä, Halil äytä.
– Ul haman da sineñ äbäñ bit.
Ul, üze telämäsä dä, üzgärgän.
Böten dönya üzgärgän kebek uk,
vakıt uzu belän keşeneñ täne dä üzgärä.

– Min anıñ şul uk keşe bulıp
kaluın telim, Filip äytä.
– Nigä aña üzgärergä kiräk?
– Bez dä üzgäräbez bit, Halil cavap birä.
– Tändä härtörle mömkin
bulgan prosesslar bar.

Miña kalsa, berkem dä omere buyı
ber ük keşe bulıp kala almıy.

– Älege zamanda äbä bik açulı, Filip äytä.
– Äti anı aktiv bulırga öndi.
– Haräkät ul baş miyen
eşlätep tora, äti äytä.
– Läkin äbä panikaga kerä yäki
bötenläy säbäpsez açulana, Filip östi.
– Eşeñ ciñel tügel, Halil äytä.

Filip uylap kala.
Mäktäptä ukıtuçılar karar kılalar.
Dikkatle bulırga kuşalar.
Sabaklarıñnı ukı.
Sportta katnaş.
Tıñla.
Öydä äti karar kıla
häm äbä ämerlär birä.
Böten vakıt Filipkä ni
bulsa eşlärgä kiräk.

Äni kön sayın şaltırata.
– Äbä turında añlatma, äti kisätä.
– Ul borçıla gına.
– Siña ukıtuçılarga
söylärgä kiräk, Halil äytä.
– Siña avır bulagannı añlıylar bit.

– Min alay uylamıym, Filip äytä.
– Alar miña kıçkıralar gına.

Bu vakıtlarda Filip härnärsägä
häm härkemgä açulana.
Halil iñbaşın sikertä.
– Çik kuy, diyä.
– Nigä äbäne kemgä bulsa başkaga
kararga birmisez?

– Berni dä añlamıysıñ,
Filip töyelep äytä.
Läkin döres uylamaganın eçennän belä.
Ul çiklär kuymıy.
Ul halennän kilmägänne eşlärgä tırışa gına.
– Küpme dävam itär bu?
Filip uylıy.
– Küpme ätiyeñneñ halennän kiler?
Halil sorıy.
– Sineñ köçen küpmegä citär?

– Äbäm turında bit süz bara, Filip äytä.
– Bez anı çitkä kaldıra almıybız.
– Kaldırmıysız bit, ägär dä
döres karar kılsagız, Halil äytä.

– Döres karar nindi?
Filip sorıy.

Halil başın çaykıy da:
– Anı äytä almıym, ämma
sez karar kılırga tiyeş, äytä.

Sägat öçtä äti şaltırata.
– Äbä yanına bara alasıñmı?
sorıy.
Filip däşmi.
– Min kiräkle ber cıyılışta.

Äbägä barganda Filipneñ
yöräge taş kebek avır.
Ul teläbräk yoklar gına ide.
Äbäneñ öy işegen açıp cibärä.

Äbä kuhna idänendä yıgılıp yata.

# Bülem 11

Filip kaltıranıp kitä.
Tirän genä sulap ala da,
äbä yanına bara.
Barmakları belän äbäneñ
muyının häm kolak töben totıp karıy.
Äbäneñ yöräge tibä.
Huştan kitkän.

Filip ätisenä şaltırata,
läkin äti cavap birmi.
Annarı Ayaz abıyına şaltırata.

Ayaz abıy un minuttan soñ kilä.
Ul aşıgıç yärdäm çakırgan.
Şunda ambulans kilep tä citä.
Äbä idändä yatkan.

Filip anıñ östenä yapma salgan.
Ul üze urındıkka utırgan da, kaltırana.
– Äbäne küçerdeñme? Ayaz abıy sorıy.
– Yuk, ul yıgılgan cirendä, Filip äytä.

Ambulans yörtüçe häm Ayaz abıy
saklanıp kına äbäne taşıgıç
östenä kütärälär.

Alar anı ambulanska iltälär.
Filip häm Ayaz abıy yalgız kalalar.
Ayaz abıynıñ yakında buluı
Filipkä iminlek hise birä.

– Bez autu belän hastahanägä
kitäbez, Ayaz äytä.
Haleñ niçek?
Barısı da yahşımı?
Äye dip Filip başın kaga.
Annarı yuk dip başın çaykıy.

– Kurkındıñ ahrısı, Ayaz abıy äytä.
– Ämma äbä köçsezgä ohşamıy bit.
Nigä yıgıldı ikän,
aptırap kaldım.
Döres aşıy mikän?
– Bez peşergänne aşıy, Filip mıgırdana.
– Şulay äytä.
Läkin kem bulsa anı
üterergä tora dip tä äytä.

Ayaz abıy suıtkıçnı açıp karıy.
Anda rät-rät savıtlar
häm bankalar tora.
– Oy, Ayaz abıy kıçkırıp cibärä.
– Bu rizık ber futbol törkemenä citär ide!
– Rizıknı äti bankalarga tutıra, Filip äytä.

– Şulay äbä telägän vakıtında aşıy ala.
– Ämma ul aşamıy,
Ayaz abıy mıgırdıy.
– Aña vitaminnar häm minerallar,
älbättä, citeşmi.
Bu anıñ halen tagın da naçarayta.
Daru şkafı niçek ikän?

Ayaz ber keçkenä şkaf yanına barıp anı aça.
– Daruların da almıy ikän, äytä.
– Hale naçar bulırga tiyeş.
Monda avırtular häm psihik problemnar
öçen darular bar.
Bolardan ul hastarak kına bula.

– Äbäneñ avıruına karşı daru tabılamı?
Filip sorıy.
– Yuk, min härhaldä belmim, Ayaz äytä.
– Ämma hale yahşırak bulsın öçen
bez küp eşli alabız.
Anı muzeylarga häm
kürgäzmälärgä alıp barırga kiräk.
Annarı ul elekkege
kebegräk bulırga mömkin.
Tirä-yagında keşelärneñ buluı da kiräkle.
Bälki dä ara-tirä massaj
häm dikkatle karau.
Muzıka, biyü häm tışta yörü.

Yahşı keşelär häm küñelle söyläşülär.
İñ möhime, döres aşarga kiräk.

Ayaz abıy häm Filip hastahanägä kerälär.
Äbä zur yatakta yata.
Uyangan, bik söyläşä almıy.
Filip anı kulınnan tota, äbäy çırayın sıta.
‒ Avırttıra, avırttıra, diyä.
‒ Kayçan bulsa hale yahşırak bulırmı?
Filip acäplänä.

‒ Yahşırak bula ala. Läkin berkayçan da
bötenläy sälamätlänmi,
Ayaz cavap birä.
‒ Bik yaman çir inde, Filip mıgırdana.
‒ Filip, iñ möhime äle bez
anı mömkin kadär yahşı karıyk,
Ayaz äytä.
‒ Bezgä çınbarlıknı kabul itärgä kiräk.
Dementianı niçek tuktatırga,
anı älegä berkem belmi.

‒ Min ülärgä telim, äbä mıgırdana.
Filip eçendäge salkınlıknıñ tamakka
kütärelüen sizä.
‒ Äbä, siña ülärgä yaramıy,
Filip kıçkırıp cibärä.
Siña sälamätlänergä kiräk, işetäseñme?



# Bülem 12

İkençe könne Filip belän Halil
mäktäp bakçasında
eskämiyädä utıralar.

– İrtägä äbäne hastahanädän
kartlar yortına küçerälär,
Filip añlata.
– Ayaz abıy monı caylagan.
Äbäne äle köpşä aşa aşatalar.
Läkin tizdän ul
adättägeçä aşıy alaçak.

– Äniyeñ ni äytä?
Halil sorıy.
– Başta telämäde,
Filip añlata.
– Bibinur apa isterikaga birilde.
Cide tapkır şaltırattı häm dä
ätigä akırdı-bakırdı.
Annarı kuzinım Sofia
anıñ telefonın yäşerde.
Ul bezneñ karar belän kileşä.

– Sin ni uylıysıñ? Halil sorıy.
– Kartlar yortı äbä öçen iñ yahşısı.

Äni dä monı añlıy,
ämma apaga kübräk vakıt kiräk,
Filip äytä.

‒ Ä abıyıñ?
Ul ni äytä?
Halil acäplänä.
‒ Abıy şat, Filip cavap birä.
‒ Äle äbäne yahşı karıylar.
Abıyga änine yuatırga da,
Bibinur apanı tınıçlandırırga da kiräk.

‒ Şeltälär belän ni eşliseñ?
Sabaklarıñnı ukımaganıñ
öçen berne aldıñ bit.
Annarı ikençesen matematika
däresendä yokıga
kitkäneñ öçen, Halil äytä.
‒ Alarnı äniyeñä kürsätteñme?
‒ Yuk, di Filip, yöze kızarıp kitä.

‒ Filip, bolar oyat tügel bit.
Başkalarnıñ da äbiläre yäki babayları
dementia belän avırıy,
Halil äytä.
‒ Bu baytak yış problem.
Sin nigä ukıtuçılarga häm rektorga
äbäñ turında añlatmıysıñ?

– Hm, Filip äytä.
– Bälki dä.

– Sineñ ayebeñ yuk närsädän
oyalma inde, Halil äytä.
– Sin beläseñme, nik beräülärgä
dementia bula ikän, Filip acäplänä.
– Kartayganda tänneñ himiyäse üzgärä,
Halil cavap birä.

– Sin haman da şul himiyä turında
uylıysıñ, Filip yılmaya.
– Muskullar, söyäklär häm
kan tamırları kebek närsälär
turında da şulaymı?

– Älbättä, Halil cavap birä.
– Läkin keşe sälamät yäşäsä,
dementiadän aldan saklana ala.
– Berkem dä tulı ışanıçlık birä almıy,
Filip äytä.
– Äbä berkayçan da elekke
kebek bulmıy dip abıy äytä.
Niçek alay bula ala?
Niçek keşe bötenläy üzgärä ala,
şunı äytergä telim?

– Baş miye, Halil äytä.

– Baş miye üzgärä.
Niçek häm nigä,
anı berkem dä belmi.
Tämam cir şarı kebek.
Klimat nigä üzgärä,
teoriyälär bik küp.
Läkin älegä bez bu turıda
bik az beläbez.

Filip belän Halil ber
mizgel äkren toralar.
– Beläseñme min ni uylıym?
Filip sorıy.
– Dementia eçtäge toman kebek.
Toman töşkäç, böten dönya yukka çıga.
– Ni äytergä teliseñ?
Halilneñ ise kitä.

– Ber närsä dä kürep bulmıy,
başkalar kayda ikänne belep bulmıy.
Kayvakıt toman açıla da,
kemne bulsa da kürep bula.
Annarı toman tagın töşä,
Filip añlata.
– Şunda tirä-yaktagı dönya belän
elemtä yugala.

Halil uylıy.

– Bu akıllı fiker, äytä.
– Miña kalsa, toman eçkä töşkändä,
keşe üzen bik yalgız
häm küñelsez his itä.
Häm dä ciñel sataşa.

Filip äkren utırıp tora.
Ahırda äytä:

– İrtägä minem belän äbä yanına
kartlar yortına barırga teliseñme?
Bälki bez aña toman
eçendä döres yulnı tabarga
yärdäm itä alırbız.
Anıñ yaratkan muzeyena barsak.
Ni uylıysıñ?



**Filipneñ äbäse elekke kebek tügel.
Ul öydän kaçkalıy,
akçasın urlıylar dip şiklänä.**

**Filipneñ ailäsenä äbä turında
möhim karar kılırga kiräk.
Fikerläre hıyallar gına mı?**

**Äbäne karaunı niçek başkarırga,
alarga uylarga kiräk?
Berkönne Filip äbäsen
idändä yıgılıp yatkan kileş taba.**

2 ciñel tel

978-952-7334-46-1

ISBN 978-952-7334-46-1 (Kägaz kitap)
ISBN 978-952-7334-47-8 (E-kitap, PDF)

**aybagar.eu ∘ bokpil.eu**